**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАРАТУН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2020 ел, 25 май N245

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәнең кайбер пунктларының гамәлдә булуын туктатып тору хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 1 апрелендәге 103-ФЗ номерлы Федераль законына таянып Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге советы **карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Каратун авыл җирлеге советының «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Каратун авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 8 ноябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Каратун авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәнең түбәндәге пунктларының гамәлдә булуын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга:

- 15 статьяның 2 пункты;
- 15 статьяның 3 пункты;
- 27 статьяның 3 пункты;
- 27 статьяның 4 пункты.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Каратун авыл җирлегенең мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Каратун авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Каратун авыл**
**җирлеге Башлыгы** **Р.Р. Сабирҗанова**